| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 сентябрь г.Казань № 863

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче; 2017 ел, 22 февраль, 113 нче; 2018 ел, 14 май, 354 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә

карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$3^1$ нче пунктта:

беренче абзацта «коммерциягә карамаган оешмаларга» сүзләрен «субсидия алучыларга» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацта татар текстында «үзгәртеп оештыру, бетерү яки банкротлык процессында булмаска» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаска» сүзләренә алыштырырга, «бетерү процессында булмаска» сүзләреннән соң «, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

$3^2$ нче пунктта:

беренче абзацта «коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен «субсидия алучылар» сүзләренә алыштырырга;

җиденче абзацта татар текстында «ябылу» сүзе алдына «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен өстәргә, «банкротлык» сүзен төшереп калдырырга, «тормавы» сүзеннән соң «, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы» сүзләрен өстәргә;

$3^4$ нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар тарафыннан тапшырылган документларның таләпләргә туры килмәве яки бу Тәртипнең $3^2$ нче пунктында каралган документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);»;

$3^6$ нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^6$. Субсидия күләме (С), шундый ук товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_{от} + З_{отвс} + З_{мто} + З_{ос} + З_{у},$$

монда:

$З_{от}$ – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне исәпкә алып, хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$З_{отвс}$ – бәйсез экспертларның, штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$З_{мто}$ – чараларны матди-техник тәэмин итүгә чыгымнар;

$З_{ос}$ – төп чараларны сатып алуга чыгымнар;

$З_{у}$ – эшләр башкару һәм хезмәт күркәтүләр өчен түләү чыгымнары.»;

4 нче пунктның икенче абзацында татар текстында «чыгымнар төрләре» сүзләреннән соң «, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе» сүзләрен өстәргә, «субсидиядән файдалану турында» сүзләреннән соң «һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында, алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары (кирәк булганда)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ нче пункт өстәргә:

«4[1]. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү;

үткәрелгән семинарлар, конференцияләр, конкурслар һәм башка чаралар саны, берәмлек;

семинарларда, конференцияләрдә, чараларда катнашкан затлар саны, кеше;

хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне исәпкә алып, эш хакы, матди бүләкләү һәм хезмәт өчен түләү буенча башка түләүләрне алган хезмәткәрләр саны, кеше;

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының бүләкләнә торган хезмәткәрләре саны, кеше;

бастырып чыгарылган журналлар, бюллетеньнәр, белешмәлекләр саны, берәмлек;

сатып алынган төп чаралар саны, берәмлек.»;

5 нче пунктта «килешү» сүзе алдына «субсидия бирү турында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 6[1] нче пункт өстәргә:

«6[1]. Субсидия алучылар квартал саен Министрлыкка хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертергә тиеш.»;

7 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән, бюджет акчасын алучы буларак баш эш итүче һәм дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүенең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртип белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешмәгәндә.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

Форма

20__ елның «__» __________ хәленә карата Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

Коммерциягә карамаган оешма ___________________________________________
Тапшыру вакыты: хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Чараның исеме | Үлчәү берәмлеге | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тай-пылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе ____________ ______________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы _______________ _________________________________ _______________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (телефоны)

20__, «__» ________

________________________________